# КАРАР

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы

Балтач авыл җирлеге Советы

«04» февраль 2022 ел. №39

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Балтач авыл җирлегендә
генераль план әзерләү
кирәклеге булмау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге территориясендә җирлек территориясеннән гамәлдәге файдалануны үзгәртү күздә тотылмаганга күрә, комплекслы социаль-икътисадый үсеш программасы һәм Татарстан Республикасы һәм Кама Тамагы муниципаль районының территориаль планлаштыру схемалары белән расланган федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру каралмаганлыктан, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл жирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең генераль планын 2025 елның 31 декабренә кадәр эшләү зарурлыгы булмавын танырга.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 4 февралендә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Кама Тамагы Муниципаль районы
Балтач авыл җирлеге башлыгы Д.И. Мухамадуллин